РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**СОВЕТ**
**Большекармалинского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул.Центральная, 4,с.Большие Кармалы, 422830
тел. (8277)35-2-38, факс: (8277) 35-2-38
ОКПО 04308893 ОГРН 1021605953951
ИНН/КПП 1622001788/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Олы Карамалы**
**авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

Узэк урамы , 4,Олы Карамалы авылы, 422830,
тел. (8277)35-2-38, факс: (8277) 35-2-38
ОКПО 04308893 ОГРН 1021605953951
ИНН/КПП 1622001788/162201001

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.11.2020 № 4

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Олы Карамалы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 03 декабрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Олы Карамалы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясе, Олы Карамалы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлар), Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясендә яшәүче, җирлек территориясендә тавыш бирергә хокукы булган, яшәү урыны буенча турыдан-туры теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Олы Кармалы авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Олы Кармалы авылында юлларны кардан чистарту, тигезләү (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Җәйге чорда Олы Кармалы авылы территориясен чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә (бастырып чыгарырга):

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Карамалы авылы, Үзәк урамы, 4;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәрлегуҗа авылы, Тукай урамы, 16,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуника-ция челтәрендә 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Олы Карамалы авыл җирлеге
башлыгы Э.И.Байдамшин